Галим, З.  Шәһәрне җыештырабыз / З. Галим // Шәһри Чаллы. – 2024. – №23 (3 апрель). – Б. 2.

# Шәһәрне җыештырабыз

Санитар икеайлык

Зөлфия **Галим**

**1 апрельдән 31 майга кадәр Чаллыда язгы санитар чистарту, яшелләндерү айлыгы башланды.**

Урамнарны, паркларны, тукталыш павильоннарын тәртипкә китерергә кирәк. Быел барлыгы 5500 агач һәм куак утыртырга планлаштыралар. Шәһәрне 1 миллионнан артык төр чәчәк, шул исәптән вазоннарда 4410 петуния бизәячәк.

Коммуналь техника санитар чистартуга әзер. Үсемлек калдыклары «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль предприятиесе карьерында кабул ителә. Чүп һәм яфрак яндыру катгый тыела.

Йортлар янында, яшел зоналарда һәм проспект кырыйларында шиннар җыю урыннары булдырылган. Шиннарны «Автомобиль юллары» һәм «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль предприятиеләре хезмәткәрләре җыеп, шин үзәгенә тапшыра.

Җитәкче шәхси секторда һәм шәһәр янындагы 16 бакчачылык ширкәтендә халыктан территорияләрен тәртипкә китерергә сорады.

Шулай ук фонтаннарны җәйге сезонга әзерли башладылар.

«9 Майга кадәр чәчәкләр шәһәребезне ямьләргә, парк, скверлар чистартылырга, һәйкәлләр, эскәмияләр, чүп савытлары буялырга һәм һәрвакыт тәртиптә булырга тиеш», – дип искәртте Илья Зуев. Ул 20 апрельдәге өмәгә кадәр шәһәрне чистартырга һәм шәһәрдәшләрне чисталыкны тәэмин итәргә чакырды.

Шәһәр мэры Наил Мәһдиев барлык предприятие һәм оешма территорияләрен тәртипкә китерү эшенә бүгеннән үк керешергә, башкарма комитет җитәкчесе Фәрит Сәлаховка бу эшне тиешле дәрәҗәдә оештырырга кушты. «Шәһәребезне чистарту эшендә актив катнашырга кирәк. Башкарма комитет, район хакимиятләре хезмәткәрләре халыкка үрнәк күрсәтергә тиеш», – диде ул.